СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2022 Баулы шәһәре №153

Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карарына өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Баулы муниципаль районЫ Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышу) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карарына (2021 елның 14 декабрендәге № 96 карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

6 статьяда:

1 пунктта «мәгълүмат стендында мәгълүмат системалары» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле « ,шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә, «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр

(функцияләр) федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - Бердәм портал) урнаштыру» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бердәм порталда Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге халкына хәбәр итү максатларында ачык тыңлаулар билгеләү һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты турында мәгълүмат урнаштыру Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан, Бердәм порталның кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органының шәхси кабинетыннан файдаланып (алга таба - органның шәхси кабинеты), әлеге нигезләмәдә билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла»;

7 статьяның 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы юлы белән җибәрергә хокуклы.

Фикер алышуга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләр тарафыннан “Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланып кертелә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын һәм ачык тыңлауларны билгеләү турында мәгълүматны бастырып чыгарган көненнән башлана һәм ачык тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертелгәндә «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләр шулай ук үзләренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен таныклаучы төп документның реквизитлары, туу датасы һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында белешмәләр җибәрәләр.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.»;

7 статьяның 9 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре, күрелгән карар нигезен дә кертеп, бастырып чыгарыла, шулай ук Баулы муниципаль районы сайтында һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында ачык тыңлаулар үткәрелгән көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе — И.И. Гозәеров